**ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР**

**24 гыйнвар 2007 ел** **№ 9**

# ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА ЭШЛӘҮЧЕ ҺӘМ ЯШӘҮЧЕ АЕРЫМ КАТЕГОРИЯ ГРАЖДАННАРГА ТОРАК ҺӘМ КОММУНАЛЬ ХЕЗМӘТЛӘР ӨЧЕН ТҮЛӘҮ БУЕНЧА СОЦИАЛЬ ЯРДӘМ ЧАРАЛАРЫ ТУРЫНДА

«Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләргә түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында» 2005 елның 20 апрелендәге 192 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә карар бирәм:

1. 2007 елның 1 гыйнварыннан түбәндәге Чирмешән муниципаль районының муниципаль учреждениеләре белгечләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чараларын билгеләргә:

- педагогик хезмәткәрләргә, мәдәният хезмәткәрләренә, шул исәптән социаль хезмәт күрсәтү, муниципаль система, социаль хезмәтләр учреждениеләрендәгеләргә, шулай ук пенсиягә чыккан хезмәткәрләргә, әгәр алар Чирмешән районы территориясендә урнашкан белем бирү учреждениеләрендә, мәдәният һәм социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә 10 елдан күбрәк эшләсәләр һәм шунда яшәсәләр;

- табибларга, провизорларга, урта медицина һәм фармацевтика белеме булган хезмәткәрләргә, муниципаль системаның, социаль хезмәтләрнең медицина хезмәткәрләренә, турыдан-туры социаль-медицина хезмәте белән шөгыльләнүчеләргә, шулай ук пенсиягә чыккан хезмәткәрләргә, әгәр алар Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә урнашкан медицина учреждениеләрендә, социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә 10 елдан да күбрәк эшләсәләр һәм шунда яшәсәләр.

2. Муниципаль учреждение җитәкчеләренә: мәгариф (Батыршина М.Т.), сәламәтлек саклау (Сәгыйров Г.Г.), мәдәният (Галимов И.Б.) һәм социаль хезмәт (Гыйләҗева Ф. Т.) хезмәткәрләр белән тиешле аңлату эшләре алып барырга, шулай ук субсидияләр-ташламалар алучылар турында мәгълүматларның мәгълүмат базасын формалаштырырга.

Муниципаль район башлыгы М.ШАКИРОВ